وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт


№12 (129). 23 март 2012 / 1-җөмәдел-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Үз илең - гөлстан ▷2◁



Хиҗап турында сүз катуны туктатыйк ▷2-3◁




Бәхетле булырга вакыт ▷3-4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**МӨФТИ ТР ПРЕЗИДЕНТЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашты. Анда шулай ук ТР Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин да катнашты.

И.Фәиз һәм М.Гатин Президентка Төркия Республикасының Дини эшләр идарәсенең рәсми чакыруы буенча Төркиягә оештырылган сәфәр турында сөйләде, идарә җитәкчелеге белән дин өлкәсендә бердәм хезмәттәшлек турында килешүне җиткерде. Очрашуда шулай ук Татарстандагы мөселман өммәтенең торышы да каралып үтте.

**БӨГЕЛМӘДӘ МИНИСТРЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**

Бөгелмә районы эчке эшләр идарәсе бинасында ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре җирле дин әһелләре белән очрашты. Очрашуда район имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин чыгыш ясады. Ул дин нигезләре, сабырлык, толерантлык турында сөйләде, хокук саклау хезмәткәрләренең халык алдында гына түгел, Аллаһы Тәгалә каршында да җавап тотачаклары турында искәртте. Соңыннан Георгий Победоносец храмыннан Георгий атакай чыгыш ясады, ул исә Библиядән өзекләр китерде һәм изге Китапны Эчке эшләр министрлыгы китапханәсенә бүләк итте.

**АССОЦИАЦИЯ ПРОЕКТЛАР ӨСТЕНДӘ ЭШЛИ**

Мөселман эшкуарлары ассоциациясенең чираттагы утырышында бизнеста хезмәттәшлек мәсьәләсе һәм яңа проектлар каралды.

Ассоциация президенты Р.Гафуров Инвестиция үсеше агентлыгы белән хезмәттәшлек итәргә тәкъдим итте, шулай ук оешманың грантлар алуда катнашу мөмкинлеген билгеләп үтте.

Ассоциация вәкиле И.Зарипов билгеләп узганча, Мөселман эшкуарлары ассоциациясенең 2012 елда үткәрәсе чаралары, шул исәптән, коммерциячел һәм социаль яктан әһәмиятле булган проектлар ("Икенчел базар", "Дәүләт флагы" кебекләр) белән таныштырды.

"Татарстан Республикасы Вакыфы"ның генераль директоры Г.Гыйбадуллин фондның инвестицияләр таләп итүче яңа проектлары турында хәбәр итте. Р.Гафуров Татарстан мөфтиятенең Мөселман эшкуарлары ассоциациясе белән берлектә наркотикларга һәм исерткеч эчемлекләргә бәйлелеге булган кешеләрне тернәкләндерү өчен махсус үзәк булдыру кирәклеген билгеләп үтте.

**ЛЕНИНОГОРСК ИМАМНАРЫ БЕЛЕМНӘРЕН АРТТЫРА**

РИУ каршындагы Имамнарның квалификациясен күтәрү үзәгенә Лениногорск районы имамнары килде. Районның төрле авыл җирлекләреннән җыелган 13 имам биредә 1 апрельгә кадәр белем алачак.

**КАБАН АРТЫ МӘЧЕТЕ ЛАГЕРЬ ОЕШТЫРА**

Казанның Кабан арты мәчете мөселман балалары өчен "Изге юл" дип аталган лагерь оештыра. Әлеге лагерь 24 марттан 31 мартка кадәр эшләячәк.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# "Аллаһы Тәгалә безгә дин әһелләренең яңа буынын тәрбияләүдә көч һәм сабырлык насыйп итсә иде"

***22 март көнне Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам университеты бинасында беренче тапкыр Татарстан Республикасы мәдрәсә укытучыларының республика киңәшмәсен уздырды.***

***Татарстанда мөселман белем бирү системасы мәчетләр каршындагы курслар белән башланып, Россия ислам университеты белән тәмамланырга - тулы, калыплашкан система барлыкка китерергә тиеш. Бер фикердә булып, ата-бабаларыбыз традицияләренә тугры калып, Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүдә бердәм юл сайларга тиешбез. Бу хакта Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте Россия ислам университеты бинасында беренче тапкыр узган Татарстан Республикасы мәдрәсә укытучыларының республика киңәшмәсе вакытында хәбәр ителде.***

***Әлеге киңәшмәдә Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, республика мәдрәсәләре укытучылары һ.б. катнашты. Узган елны мөфтият мәчетләр каршында эшләп килүче курсларның укытучыларын җыеп киңәшләшкән иде.***

***Хәзерге вакытта Татарстандагы профессиональ мөселман мәгарифе системасы тәртипкә салына, бердәм стандартлар кертелә. Республиканың барлык мәдрәсәләренең оештыручысы - ТР мөселманнары Диния нәзарәте үзенең мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеген финанслый башлады, бу исә системаны тамырдан үзгәртергә, яңа дәрәҗәгә күтәрергә, мәдрәсәләрне яхшы укытучылар белән тәэмин итәргә, заманча җиһазларга мөмкинлек бирәчәк, дип уйланыла.***

**Сезнең игътибарыгызга ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗнең чыгышын тәкъдим итәбез.**

Бүген бирелгән яхшы сыйфатлы дини белем - киләчәктә җәмгыятьнең дини һәм дини булмаган өлешләре арасында гармонияле мөнәсәбәтләрнең үсешен тәшкил итәчәк.

Бүгенге көндә Татарстандагы дини белем бирү учреждениеләрендәге укыту дәрәҗәсе түбән дәрәҗәдә. Бу, ни кызганыч, тар дини фикер йөртүгә һәм башкаларга карата түземсезлеккә китерә, җәмгыять тормышында катнашуга киртә булып тора. РФ Конституциясе буенча, һәр гражданин яхшы сыйфатлы белем алырга хокуклы. Түбән сыйфатлы дини белем бирү дини белем алырга теләүче кешенең дә, дөньяви белем алырга теләүче дини кешенең дә хокукларын бозу дигән сүз.

Дин нигезләрен белмәү кешене, бигрәк тә яшьләрне, хәвефле идеологик агымнар алдында көчсез итә, башкаларга карата түземсезлеккә һәм агрессиягә китерә. Бу идеологик агымнарның факторлары буларак, Россиядә "Хизбут-Тәһрир", ваһһабчылык һәм башка исламга хас булмаган сәяси агымнар тора. Башкача әйткәндә, динне рухи үсеш функциясе түгел, ә җәмгыятьне таркату функциясе буларак куллану, киләчәктә Россия мөселман өммәтенең берлеген куркыныч астына куя.

Һичшиксез, безнең республикабызда бүгенге көндә бирелә торган дини белем бик популяр. Ләкин, шуны әйтеп үтәргә кирәк, белем бирү сыйфаты түбән дәрәҗәдә, кирәкле шартлар һәм техник җиһазлар юк. Хәзер югары дини белем алырга омтылган яшьләр аны чит илдә алырга тырыша. Аларның күбесе шунда ук эшкә дә кала.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# КОРЪӘННЕ АҺӘҢЛЕ ИТЕП УКЫГЫЗ!

**Бик күпләр Коръәнне үзенең авызына җәмәгатьне каратып торырлык итеп уку турында хыяллана: ул адәм балаларының иман нурын арттыра һәм аларны дөнья мәшәкатьләреннән, юк-бар, файдасыз, буш сүзләр сөйләүдән котылып торырга; кешегә тормыш авырлыкларына күз йомарга, рухны күтәрергә, Аллаһ белән сер булып саклана торган аралашу булдырырга ярдәм итә.**

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ



Коръәнне матур итеп укыганда тәҗвид кагыйдәләренә туры китереп, тавышыңның моңлы, ягымлы яңгыравын халык-тамашачы хөкеменә тәкъдим итәргә ярыймы? Үз адресыңа мактау сүзләре ишетү һәм Коръәни-Кәримне кабаттан уку мөрәҗәгатен кабул итү рөхсәт иteләме?

Пәйгамбәребезнең (сгв) Габдерраззак һәм башкалар тапшырган хәдистә мондый юллар бар: "Һәрбер әйбернең үз бизәге бар, ә Коръәннең бизәге булып матур тавыш тора".

Әмма Коръәнне бар ихласыңны биреп, чын күңелдән күркәм итеп уку һәр кешенең дә хәленнән килеп бетми. Нәкъ менә эчкерсез, саф, "үз" тавышы белән (бөтен кеше ишетерлек итеп, әмма шул ук вакытта "каты" кычкырмыйча) Китап укучыларга да юлыгасың. Мондый дәрәҗәгә ирешү өчен Ходай тарафыннан бүләк ителгән сәләтеңне осталык дәрәҗәсенә үстерергә һәм аны белгечләргә гел тикшертеп торырга кирәк. Аһәңле тавышыңны мактау сүзләреннән һәм рияланудан саклау алай ук җиңел түгел, әмма мөмкин эш.

Аллаһ Илчесенең (сгв) Кыямәт көнендә җавап тотачагыбыз турында әйткән васыятен истә тотарга кирәк: "Аллаһ каршына басканнан соң... фән белән шөгыльләнгән һәм бүтәннәрне гыйлемгә өйрәткән кешегә Аллаһ аңа, Үзе биргән сәләтләр турында исенә төшерергә мөмкинлек бирәчәк һәм, ул кеше, аларны таныячак. (Аллаһы Тәгалә) әйтәчәк: "Син алар белән ни рәвешле файдаландың?" Тегесе җавап бирәчәк: "Мин гыйлем алдым һәм белгәннәремне башкаларга да өйрәттем, Коръән укыдым - боларның барысы да Синең ризалыгың өчен иде. (Аллаһы Тәгалә) әйтәчәк: "Син алдалыйсың. Син, дөрестән дә, гыйлем алдың, әмма ул (синең турында) "син күп белүче" дип әйтсеннәр өчен генә иде. Һәм син (синең турында) "ул - изге Коръәнне укучы" дип әйтсеннәр өчен Коръән укыдың. (Синең турыда) шулай дип әйттеләр дә". Шуннан соң аны барасы юл буенча йөзе белән аска каратып Утлы җәһәннәмгә сөйрәргә һәм шунда ташларга кушылды".

Коръәнне ихласлык белән укучы, аерым кеше белән Аллаһ арасында чит телләрдән оста тәрҗемә итүгә охшаган, безгә күренми торган "күпер" булып калырга гына тиеш. Ул изге сүзләр дөньясында гизүче, җанны өзгәләүче, әмма үзенең "кулы" турында ни үзенә, ни әйләнә-тирәдәгеләргә искә төшерми торган үтә күренмәле озата баручы кебек булырга тиеш.

Ахырзаман Китабын уку һәм ятлау иң күркәм эшләрнең берсе булып санала, ул кешене рухи яктан баета һәм аны бик югары дәрәҗәләргә күтәрә. Аһәңле, матур уку җәннәт юлы да, җәһәннәм юлы да булырга мөмкин.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# КОРЪӘННЕ АҺӘҢЛЕ ИТЕП УКЫГЫЗ!

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә)*

Мактаганны һәр кеше дә яратканны һәм үзеңдә тәкәбберлекне җәелдермәүне дә истән чыгармау лязем.

Әбу Умамның (Аллаһ аннан разый булса иде) болай дип хәбәр иткәнлеге турында мәгълүмат бар: "Мин Аллаһ илчесенең түбәндәгеләрне әйткәнен ишеттем: "Коръән укыгыз, чөнки, дөрестән дә, Кыямәт көнендә ул аны укучыга яклаучы кебек булачак".

Тагын да исәпсез-хисапсыз әҗер-савап мөэмин-мөселманга Коръәнне ятлаган һәм, алай гына да түгел, соңыннан аны онытмаган өчен бирелүе мәгълүм. Коръән хафизлар, ягъни Коръәнне хәтердән укучылар - Илаһи Ачыш йөртүчеләрнең җанлы гәүдәләнеше. Ә бит әле Аллаһ Үзенең чиксез рәхим-шәфкате белән истә калдыру юлын тагын да җиңеләйткән: "Сезнең иң яхшыгыз шул: кем Коръән өйрәнә һәм шуны башкаларга да өйрәтә".

Имам әл-Җәзари әйткән: "Көпшә сыман итеп төрелгән кәгазьдә яисә китапта түгел, ә нәкъ менә йөрәктә Коръәнне ятлау юлы белән саклау (әлбәттә, Бөек Затның мөселманнарга бүләге) - Аллаһка ышаныч һәм мөгътәбәрлек үзенчәлегенә ишарә. Изге текстларны хәтердән белмәгән хәлдә, аларны бары тик кәгазьдә генә саклаучылар һәм шуның өчен дә аны гел китаплардан гына карап укучылар мондый Китапка ия булучыларның капма-каршысы булып торалар. Шул ук вакытта, Аллаһ Үзенең чиксез рәхмәте белән мөселманнарга шуны да бүләк кылды ки, аларның кайберләре пәйгамбәребездән (сгв) Коръәнне хәрефләп өйрәнеп, тулы һәм дөрес итеп укуга бөтенләе белән бирелделәр, бер генә хәрәкәне дә һәм бер генә сәкенне дә төшереп калдырмадылар".

Имам әл-Мәүриди билгеләп узганча, "Коръән могҗизаларының берсе - кешеләрнең кайсы телдә сөйләшүләренә бәйсез рәвештә, аның бар кеше өчен дә җиңел ятлануыннан гыйбарәт. Бер генә китап та Коръән ятланган кебек ятланмый. Бу - аңа Ходай тарафыннан бирелгән үзенчәлек, ул аны шуның белән башка китаплардан аерып тора".

Беренче карашка гына Изге Коръәнне ятлау мөмкин түгел кебек тоела. Әмма сәбәбенә керешкән кеше гел җиңә! Өстәвенә, мондый турылыклы юлдан безне Аллаһы Тәгалә Үзе җитәкләп бара.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# "Аллаһы Тәгалә безгә дин әһелләренең яңа буынын тәрбияләүдә көч һәм сабырлык насыйп итсә иде"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә)*

Бу хәл безне бик тә борчуга сала. Шунысын да ассызыкларга кирәк: чит илләрдә белемне башка мәзһәбләр буенча бирәләр, һәм студентлар укып, монда кайткан очракта, бу республикабыз өммәтендә каршылыклар килеп чыгуга китерә.

Шунысы да мөһим: безнең дини белем бирүче учреждениеләрдә Татарстаннан гына түгел, ә Россиянең башка төбәк һәм өлкәләреннән дә, БДБ илләреннән килгән егетләр һәм кызлар укый. Монда милли каршылык юк, чөнки ислам дине милләтара түземлелеккә һәм дуслыкка өйрәтә. Студентларның күпчелеге бүтән милләт вәкилләре икәнлеге дә яхшы билгеле.

Мондый уникаль мөмкинлекләр булганда, әлбәттә, без үзебезнең милләт студентлары саны артуын телибез, чөнки моның белән татарларның рухи киләчәге дә бәйле.

Укытуны татар телендә алып барырга тырышырга кирәк. Бу башка милләт студентлары өчен икенче дәүләт телен өйрәнүгә этәргеч булып торачак.

Татарстан җирлегендә иң көчле һәм танылган дини тәгълимат бирүче мәктәпләрнең берсе эшләп килгән XIX гасыр ахырын - XX гасыр башын искә төшерергә кирәк. Безгә Садри Максуди, Йосыф Акчура, Шиһабетдин Мәрҗани кебек танылган мөселман галимнәре һәм дин белгечләре билгеле. Бу җәмәгать эшлеклеләре татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер үсешенә әйтеп бетергесез зур өлеш керттеләр. Аларны татарлар гына түгел, ә Россия һәм дөнья мөселманнары да белә, китапларын өйрәнә, дәреслекләреннән файдалана.

Дин социаль институтларның торышына да тәэсир итә, халык мәдәниятен саклап калырга, үстерергә һәм аны башка буыннарга тапшырырга булыша. Башкача әйткәндә, җәмгыятьне рухи яктан үстерә.

Мөселман дини белем бирү учреждениеләренең төп максаты - милли һәм мәдәни яктан үз-үзен идентификацияләргә сәләтле булган чын мөселман кешесе тәрбияләү. Соңгы вакытта бик үк күңелле булмаган күренеш барлыкка килде - югары дини уку йортларын тәмамлаучылар башка өлкәләрдә эшли башлады. Ә бит бүгенге көндә мөселман өммәтенә югары квалификацияле кадрлар җитенкерәми: имамнар, вәгазьчеләр, ораторлар; мәчет һәм мәдрәсәләрдә - махсус белемнәре булган укытучылар, шулай ук казыйлар һәм дин белгечләре. Бу мәсьәләнең чишелеше дини уку йортларын тәмамлаучыларның бу өлкәдә эшли башлауларына бәйле.

Аллаһы Тәгалә безгә дин әһелләренең яңа буынын тәрбияләүдә көч һәм сабырлык насыйп итсә иде!

# ХИҖАП ТУРЫНДА

**Хиҗап (мөслимәләр киеме) мәсьәләсе вакыт-вакыт массакүләм мәгълүмат чараларында гына түгел, хәтта телевидение тапшыруларында да баш калкыта. Димәк, бу тема һәрвакыт актуаль булып калачак. Күп очракта түрәләрнең хиҗапка карашы утка май сипкәндәй итә.**

Еш кына мәктәп директорлары мөселман кызларына дәрескә шәригать кануннарына туры килгән кием киеп килергә рөхсәт бирми, югары уку йортлары укытучылары арасында да бу күренешкә ризасызлык белдерүчеләр күзәтелә.

Хәтта кайбер түрәләр: "Мөслимәләр эш вакытында дресс-кодны сакларга тиеш, ә башка вакытта киемсез йөрсәләр дә була", дигәнрәк фикерне дә яклап чыга. Мондый дөньяви экстремизмның асылы кая барып тоташа соң? Әллә хиҗап, дөрестән дә, кемгәдер комачаулыймы икән? Бәлки, аларга хиҗап мөслимәләрнең акыл эшчәнлегенә тискәре тәэсир итә кебек тоеладыр? Әгәр дә бу чыннан да шулай икән, күптөрле фән кандидатлары һәм докторлары арасында мөселман хатын-кызларының саны елдан-ел артуны ни рәвешле аңлатып булыр соң? Кем өчендер әле әйтелгәннәр, бәлки, чынлап та, зур яңалыктыр, ләкин безнең көннәрдә моның шулай булуы хак. Эш урынында да мөслимәләр бүтәннәрдән калышмый, хиҗап кигән мөселман хатын-кызлары фәнни оешмаларда, дәүләт учреждениеләрендә бил бөгә, икътисади эшчәнлек алып бара һәм зурдан-зур уңышларга ирешә. Хәзер "көнчыгышның изелгән хатын-кызлары" югары урыннарда эшли: оешмалар белән идарә итә, фәнни хезмәтләр яза - кайда гына булсалар да, алар дин юлында булмаган хезмәттәшләреннән калышмый.

Гомумән алганда, хиҗаптан йөрүне тыю "Намус иреге һәм дин тоту иреге турында"гы Федераль законны бозу дигән сүз. Исегезгә төшерәм, анда мондый юллар бар: "...ялгызың гына яки бүтәннәр белән бергәлектә кайсы да булса берәр динне тоту яки берсен дә тотмау, ирекле рәвештә дини һәм бүтән төрле карашларны сайлау һәм үзгәртү, аңа ия булу һәм тарату, һәм шушыларга бәйле рәвештә эш итү". Биредә үзләренең дини карашларына нисбәтле, "алар белән ярашып эш итү" турында да ачык әйтелгән. Шуны ук без кеше хокуклары турындагы Гомум декларациядә дә күрәбез. Бу декларациянең 19 нчы матдәсендә "Һәр кешенең фикер-караш ирегенә һәм аларны ирекле белдерү хокукына ия" булуы турында әйтелә. Хиҗаптан йөрү шул карашларның чагылышы түгелмени?

Хиҗап кию өчен мөселман хатын-кызларына дини нигез "ән-Нур" сүрәсенең 31 нче аятендә күрсәтелгән: "Әйт мөэминә хатыннарга, карарга ярамаган нәрсәдән күзләрен йомсыннар вә фәҗерләрен зинадан сакласыннар һәм кул белән йөзләреннән башка булган зиннәт урыннарын ачмасыннар, мәгәр һәрвакыт ачык була торган йөзләрен, ике кулларын вә тәпиләрен ачсалар ярый, һәм башларын, муеннарын вә күкрәкләрен пәрдәләр белән капласыннар, вә зиннәтләрен ачмасыннар. "Аллаһ мөселман булган хатын-кызларны чәчләрен, муеннарын, беләкләрен, тубыкларын, югары чәлтерләрен, колак алкаларын, муенга таккан зиннәтләрен һәм беләзекләрен ят ирләргә күрсәтүдән тыйды", мәгәр бу әйтелгәннәрне үзенең иренә, яки аталарына, яки ирләренең аталарына, яки үзләренең ир туганнарына, яки үзләренең балаларына, яки ирләренең балаларына, яки бертуган кардәшләренең балаларына, яки кыз туганнарының балаларына, яки мөселман булган хатыннарга, яки үзе хуҗа булган кол иргә вә кол хатынга, һәм шәһвәт куәте булмыйча хатыннарга ихтыяҗы булмаган, фәкать хатыннар янына ашар-эчәр өчен генә килә торган ят ирләргә, һәм хатыннарга якынлык кылырга көче җитмәгән, ягъни бәлагатькә ирешмәгән ир балаларга, шушы зекер ителгән кешеләргә чәчләрен, муеннарын, колак алкаларын, бел-

# ҮЗ ИЛЕҢ - ГӨЛСТАН

Безнең болгар-кыпчак бабаларыбызның бик күптәннән үз дәүләтчелеге булган. Татар халкының тарихи-милли бишеге саналган Болгар иле яисә Идел Болгарстаны IX гасырда ук төзелә. Көнчыгыш Европадагы иң беренче дәүләт була бу. Яңа ил чагыштырмача тиз арада сәяси, икътисади, мәдәни яктан нык үсеш ала. Борынгы күп кенә тарихи чыганакларда ул "Бөек Болгар" дип телгә алына. Аның башкаласы турында XI йөз галиме Мәхмүт Кашгари "Болгар - төрки шәһәрләреннән мәшһүр бер шәһәр" дип язып калдыра. Болгарны ул үзе төзегән дөнья картасында да күрсәтә.

XIII-XIV йөзләрдә Болгар Алтын Урда биләмәсендә була. Ә 1445 елда Болгарның һәм Алтын Урданың дәвамчысы булган Казан ханлыгы барлыкка килә...

Аңлашыла ки, бик электән үк утрак тормышка күчеп, мөстәкыйль илдәүләт корып яшәгән халыкның фольклорында да бу темага кагылышлы әсәрләр зур урын алып торалар. Безнең күпсанлы мәкальләребездә берләшеп, ил булып яшәүнең өстенлекләре раслана, аерым шәхеснең язмышы ил язмышы белән аерылгысыз бәйле булуы күрсәтелә:

● Күп төкерсә - күл булыр,
Күп берексә - ил булыр.
● Тау билсез булмас,
Адәм илсез булмас.
● Бердә түгел, илдә көч.
● Илгә таянган Идел кичәр.
● Ил көче - Идел көче.
● Ил аткан таш еракка китә.
● Ил белән этәргәч, тау күчкән.
● Очырырга җил көчле,
Көрәшергә ил көчле.
● Илдә булса, үлмәссең,
Илсез көнең күрмәссең.
● Иле иркеннең көне иркен.
● Ил белән килгән бәла авыр түгел.

Туган илне сөю, ватанчылык хисе - кеше күңелендәге иң изге, иң нечкә һәм иң олы хис. Халык аны әхлакый сыйфатларның иң югарысы итеп исәпли. Туган илнең якынлыгы, газизлеге турында сөйләүче мәкальләргә хистойгы тирәнлеге, самимилек хас:

● Ватан барыннан да газиз.
● Ватансыз кеше - бакчасыз сандугач.
● Туган җирдәй җир булмас,
Туган илдәй ил булмас.
● Үз илең - гөлстан,
Кеше иле - гүрстан.
● Үз илең - үз анаң,
Үзгә ил - үги анаң.
● Илем-җирем булмаса,
Аем-көнем тумасын.
● Туган туфракка баскан эз суынмый.
● Үз илем - үземә алтын.
● Илнең әреме дә хуш исле.

Соңгы мәкаль белән бәйләнештә кыпчак ханы Артык турындагы бер риваять хәтергә килә. Артык хан - "Игорь



полкы турында җыр" әсәренә дә кереп калган Кончак ханның атасы. Ул үзенең 45 меңлек атлы гаскәре белән грузин патшасы Давид IV гә Грузияне азат итүдә хәлиткеч ярдәм күрсәтә, кызын Давидка кияүгә бирә һәм, зур дәрәҗәгә ия булып, озак вакыт Кавказда гомер сөрә. Бервакыт туганы Сырҗан аны үз җиренә - Кыпчак даласына чакырырга килә. Ләкин күпме үгетләсә дә, Артык һич ризалашмый. Шуннан Сырҗан моңа куенына тыгып килгән бер учма дала үләнен суза. Кипкән әрем сабагын иснәүгә, Артык хан, бер сүз дә әйтмичә, иярләнгән аты янына ташлана. Көнетөне чабып, туган даласына кайтып җиткәч, ул: "Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул икән", дип әйткән, ди.

Әйе, ватанчылык хисен халык байлык, дәрәҗә кебек нәрсәләрдән чагыштыргысыз өстен куя. "Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык", "Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил", "Туган илдә яшәмәгән яшәү кадерен белмәс", "Былбылны алтын читлеккә япсаң да, үз тал-тирәген сагынып сайрар" кебек мәкальләр дә моны бик ачык күрсәтәләр.

Туган илдән аерылу, чит җирләрдә яшәргә мәҗбүр булу, халык карашынча, кеше башына килә торган бик зур бәхетсезлек булып санала. Мондый эчтәлектәге әсәрләр шушы фаҗигале язмышны кичергән татар халкының ачы тәҗрибә авазы кебек кабул ителәләр.

● Иң зур сагыш - Ватан сагышы.
● Читтә йөргән тарыгыр,
Туган илен сагыныр.
● Ачтан үлсәң дә, туган илеңне ташлама.
● Дөнья киң дип таралма, таралган тарыны тавык чүпли.
● Илгә сыймаган баш -
Иделгә баткан таш.
● Иленнән аерылган -
Канаты каерылган.
● Иленнән аерылган җиде ел елар,
Иленнән аерылган үлгәнче елар.

Ватанга мәхәббәт хисен халык нindидер якынча төшенчә итеп аңламый. Бу мәхәббәт кешенең эш-гамәлендә төгәл гәүдәләнеш табарга тиеш. Ватан шәхес турында кайгыртучанлык күрсәткән кебек, шәхес тә үз Ватанының иминлеге, байлыгы һәм көчле булуы турында кайгыртырга бурычлы. Менә шушы идея халыкның күп кенә мәкальләре аша кызыл җеп булып үтә. "Ил көенгәндә көен, ил сөенгәндә сөен", "Ватанга хезмәт - үзеңә хезмәт", - ди халык. Мондый мәкальләрдә без "ир-егет" шәхесе белән еш очрашабыз. Ул Ватан-шәхес мөнәсәбәтләрендә халыкның идеалын гәүдәләндерүче зат:

● Ир-егетнең яхшысы ил белән.
● Ил өметен ир аклар,
Ирнең данын ил саклар.
● Ирнең даны иленнән,
Халкы белән җиреннән.
● Ил гамен җыйган ир ил агасы булыр.
● Ир яхшысы илгә ярый.
● Ил намусы ир иңендә.
● Ил барда ир хур булмас,
Ир барда ил хур булмас.

***Хуҗиәхмәт МӘХМҮТОВ,***
***филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре***

# СҮЗ КАТУНЫ ТУКТАТЫЙК



әкләрен, беләзекләрен, балтырларын күрсәтсәләр гөнаһ булмас, вә ул хатыннар күренмәгән зиннәтләрен белдермәк өчен урамда йөргәндә аякларын аякларына бәрмәсеннәр, ягъни йөргәндә аяк тавышларын да, чылтыравыклы зиннәтләренең дә тавышларын ишеттереп йөрмәсеннәр! Ий мөэминнәр, һәммәләрегез дә Аллаһка тәүбә итегез, шаять дөнья вә ахирәттә бәхетле булырсыз". (Ногмани тәфсиреннән.)

Мөхәммәтнең (сгв) фикере бу аятькә ачыклык кертә: "Әбу Давыд Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булса иде) тапшыра: Әбу Бәкер кызы Әсма пәйгамбәребез (сгв) янына юка, үтә күренмәле киемнән керә. Пәйгамбәр (сгв) аннан башын ала һәм болай ди: "Әй, Әсма, женси яктан җитлегү чорына кергән хатын-кызга менә бу ике җирдән кала, бүтән бер җирне дә кешегә күрсәтеп йөрү рөхсәт ителми", - дип, йөзгә һәм кул чукларына күрсәтә.

Күрүебезчә, Ислам, дөрестән дә, мөселман хатын-кызларына йөз һәм кул чукларыннан кала бөтен тәнне каплап йөрергә боера. Һәм, кемдер аларны шулай киенеп йөрергә мәҗбүр итәдер, дип уйларга кирәкми, бу аларның ихтыяри һәм ихлас күңелдән булган шәхси сайлаулары.

Кайберәүләр, хәзерге мөслимәләр киеп йөргән кием татар хатын-кызларының традицион киеменә туры килми, дип дәгъва белдерә. Мондыйларга: "Гафу итегез, ә сез үзегез гореф-гадәт буенча киенәсезме соң?" дип сорыйсы килә. Борынгыдан килгән гадәт буенча, татар хатын-кызлары, чынлап та, зур, ачык изүле күлмәкләр һәм кыска итәкләр кигән микәнни? Җаны теләгәнчә киенү һәр кешенең үз ихтыярында. Әйе, дөрестән дә, заманча яулык бәйләү алымнары безгә XX йөзнең туксанынчы елларында гарәп илләреннән яисә Төркиядән үтеп керде, кайберсе үзебезнең дизайнерлар тарафыннан эшләнде. Ни өчен гореф-гадәтләр дип җан атучылар бу турыда шул 90 нчы елларда уйланмаган соң? Ни өчен алар көнбатыш киемнәренә өстенлек биргән?


Дини экстремизм туу сәбәпләренең берсе булып, бәлки, мөселман хатын-кызларының кием турындагы ялгыш фикер дә зур роль уйныйдыр. Җәмгыятьнең Исламга булган мондый мөнәсәбәте кайбер мөселманнарда җәмгыятькә каршы фикер уята: алар конституцион тәртипне алмаштыру зарурлыгы турында пропаганда алып бара башлый, ә кайберәүләр, бернигә дә карамыйча, чит илләргә күченеп китә.

Башка илләр мисалына мөрәҗәгать итсәк, бездә хәлләр алай ук мөшкел түгел. Ике меңенче еллар башында мөслимәләр паспортка яулыктан фотога төшү хокукына иреште. Безнең ил законнары буенча, мөслимәләргә җәмәгать урыннарында да шәригать кушканча киенеп йөрү тыелмый. Франциядә, мисал өчен, бу дәүләт тарафыннан тыелган бит. Әмма Бөекбритания кебек демократик илләр дә бар - анда полициядә эшләүче хатын-кызлар (мөслимәләр) өчен махсус форма тегелгән. Шунлыктан, төп мәсьәлә хиҗапта гына да түгел, ә безнең аңа булган карашыбызда. Әйдәгез, бер-беребезне ничек бар, шулай кабул итик әле. Беренчел стереотипларны үзгәртик. Әгәр дә хәзерге моментта толерантлык турында сүз алып бару гадәткә кергән икән, бер-беребезгә тагын да ихтирамлырак булсак иде.

***Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, тарих фәннәре кандидаты***

## Яңа китап

"Иман" нәшриятында Әхмәтһади Максудиның "Мөгаллим сәни" исемле китабы дөнья күрде. Моңа кадәр басылганнарыннан исә ул хәрефләре белән аерылып тора. Мәгълүм ки, татарлар ислам мәдәнияте тарихында беренче басма Коръәнне нәшер иткән халык. ("Казан басмасы" исемле гарәп шрифты белән басылган Коръәнгә быел 225 ел булачак.) "Иман" мәркәзе шушы "Казан басмасы" шрифтын компьютерлаштырды һәм шуның нигезендә "Мөгаллим сәни" китабын бастырып чыгарды.




## Иман нуры сүнгәндә

Төн караңгысы дөньяны каплаган бер мәлдә ут сүнде. Шәмне табам дип, кап-караңгы өйдә дивар-ишекләрне капшый-капшый йөргәндә, күңел шомлы уйлар белән тулды: Җир йөзендә сукыр кеше ничек яши икән… Барыр юлын табу аңа шундый кыендыр инде…

Ниһаять, табылган шәм йомшак, игелекле нурлары белән бүлмәбезне яктырта башлады. “Менә бит, бу яктылык – Аллаһның олуг рәхмәте” дигән фикер тәэсирендә күңел тынычланып китте, сөенеч һәм шөкер хисләре бөек, юмарт Яратучыма юнәлеп, бар җиһанны яктырткандай булды…

Тылсымлы, җанымны иркәли торган шәм яктысында уйланып утырам. Адәм баласына маңгай күзе белән күрү сәләтеннән тыш, күңел күзе белән күрү мөмкинлеге дә бирелә. Әмма күпләрнең күңел күзе, кызганычка, ябык. Бүген өебездә электр уты сүнгән кебек, кайбер инсаннар күңелендә иман нуры сүнгән. Җан-калебләрендә – караңгылык. Рухын чүп-пычрак басканын андый кеше тоймый, хәрам белән хәләлне аермый һәм шул сәбәпле, үзенә зыян китерә торган нәрсәләрне белеп аера алмый.

Әле менә бер гыйбрәтле кыйсса искә төште. Тәрәзәсе пычракка батып беткән караңгы бүлмәдә бер егетне бикләп калдыралар. Бераз вакыт үткәннән соң, аннан: “Йә егет, ничек анда сиңа, уңайсыз түгелме?” – дип кызыксыналар. Тегесе: “Юк, биредә караңгы булса да, бик рәхәт: җылы, тыныч, уңайлы”, – дип җавап кайтара. Урамнан тәрәзәгә бер чүмеч су тондыралар. Тәрәзә пыяласыннан пычрак бераз юылып төшә дә, бүлмәгә аз гына яктылык үтеп керә башлый. Шуннан соң егет аптырашлы тавыш белән борын астыннан гына әйтеп куя: “И-и, монда диван асты өскә килеп әйләндерелгән бит… Өстәл белән шкаф та ауган икән…”

Тәрәзәне икенче чүмеч су белән “коендыралар”. Пычрак тәрәзә тагын да ачылып китә һәм яктылыгы арткан бүлмәдә ватык урындыкларны, тузгып яткан китап-газетларны күреп, егетебез шакката: “Менә сиңа мә! Монда коточкыч икән бит, җәмәгать!”

Ә инде тәрәзәгә өченче чүмеч су орылгач, егет ирексездән хәтта кычкырып җибәрә: “Каравыл! Бүлмә тулы таракан, лыгыр пычрак, пәрәвез! Тизрәк чыгарыгыз мине биредән!!!”

Их, безнең дөнья сазы белән капланган күңел “тәрәзәләребезне” дә юасы иде. Күңелгә нур-яктылык үтеп керә башлагач, без дә анда җыелган пычракны, чүпне, анда хасил булган тәртипсезлекне күрә алыр идек. Тик нәрсә белән пакьләргә соң күңелне? Дөнья суы бит бу эшкә ярамый. Хикмәтле Тукаебыз да:

“Керләнә өст-өстенә рух,
Һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәпле җир йөзендә
Тәнгә – мунча, җанга юк?!”

– дип борчылган бит. Шулай да, бар ул, дускайлар, калеб мунчасы, бар. Йөрәк-җаныбызны пакьләүче нәрсә – ул дин. Ләкин бүген бик күп кеше “дин – муллалар өчен генә ул” дигән фикер белән яши. Кайберәүләр исә гаиләкорганда, бала туганда яки берәр туганы вафат булганда мулла чакыруны яки елына ике гаеткә барып кайтуны дин дип белә. Әмма бу – чын, тулы дин түгел. Дин ул – тормыш рәвеше, ул Яратучы кушканны һәм тыйганны һәрдаим истә тотып яшәү, Аңа буйсыну. Нәкъ менә шушы динне өйрәнеп аны гамәлгә кертү, изге китап Коръәни-Кәримне уку җаныбызны сафландыра да инде.

# БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ВАКЫТ




### Дин буенча яшәсәк…

Көн бүген мәшәкатьле булды. Шуның өстенә берәү белән яшәү мәгънәсе турында сөйләшеп, аның “фәлсәфәсен” тыңлаганнан соң, кәеф бераз кырылды. Янәсе, диннән башка да ул бик әйбәт яши! Ә Аллаһы Тәгаләдән башка, Ул даими биреп торган һава, ризык, су, сәламәтлек һәм башка бик күп нигъмәтләрдән башка яши алмаганын оныткан... Яшәешнең төп максатын, шушы дөнья төзелеше хикмәтен әлегә аңлап бетермәгән шул бәндә белән шактый сүз куерттык без бүген.

“Иң кадерле нәрсә – сәламәтлек”, – диде ул. “Әмма аны Аллаһтан башка беркем дә бирә алмый!” – дип җавап бирдем мин.

Без барыбыз да бу дөньяда фәкать Аллаһ рәхмәте белән яшибез! Без – исән. Йөрәкләребез дистәләрчә еллар буе тибә, тәнебез буйлап тонналаган кан әйләндерә. Ничек шулай бертуктаусыз эшли соң ул? Батарейкалар да алыштырасы юк, телефонны кебек вакыт-вакыт электрга тоташтырып алу да таләп ителми…

Сантехника кибете каршында очраштык без танышым белән. Тышта 25 градус салкын, ә аның фатирындагы җылылык торбасы тишелгән икән, шуны кайгыртып, ремонтлыйм дип йөрүе. Әйе шул, дидем мин, кечкенә генә фатирны җылытыр өчен дә күпме чимал, хезмәт, финанс чыгымнары кирәк. Ә Аллаһы Тәгалә Үзенең кояшы белән бөтен Җир шарын җылыта. Өйдәге җылылык системасы кешегә мохтаҗ булган кебек, дөнья җиһанын яктыртып, җылытып торучы система да Караучыга мохтаҗ. Ә Аллаһы Тәгаләдән башка аны беркем дә тәртиптә тота алмый. Фәкать Аллаһ рәхмәте белән генә Җир шарында кеше тәне түзәрлек салкынлык яисә эсселек була. Аллаһ Раббыбыз безгә сәламәтлек, Җир йөзендә яшәрлек шартлар, татлы ризыклар тәмен тою мөмкинлеген, акыл, ишетү, күрү – башка бик күп нигъмәтләрне бүләк итә. Шулай булгач, безнең тормышыбыз – тулысынча Аллаһ карамагында. Ләкин моны аңлап шөкер итүчеләр күпме соң бүген?

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ВАКЫТ

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә)*

Берәү күз күрүе начараю сәбәпле, хастаханәгә барып тикшеренә дә, күзлек сатып ала. Аннары исә шул күзлекне биргән табибны искә алган саен аңа рәхмәт укый. Ә күзне, бу дөнья матурлыгын, туганнарын, баласын күрү бәхетен бүләк иткән Аллаһка шөкер итү юк...

Искиткеч матур табигать күренешләрен чагылдырган рәсемнәргә карап сокланабыз, шул рәсем авторларын – рәссамнарны мактыйбыз, данлыйбыз, ләкин шушы табигатьне шундый гаҗәеп дәрәҗәдә гүзәл итеп юктан бар иткән Яратучыны искә дә алмыйбыз.

...Танышым борын астыннан гына елмаеп болай диде:

– Табигате, дөньясы матур инде матурын, ләкин син әйткән кояш, гомумән, бу дөнья һәм кеше үзеннән-үзе көйләнеп бер җайга салынган система ул. Боларны Аллаһ бар итеп бер тәртипкә урнаштыруын исбатларга, нигезләргә кирәк бит әле. Дәлилсез сүз боткасы ясаудан ни мәгънә?

– Менә уйлап кара, – дидем мин аңа, – әгәр кибеткә кереп киштәләрдә төгәл, матур итеп урнаштырылган әйберләргә күз салсак, алар бирегә үзләре, кибет хуҗасы катнашыннан башка гына тезелешкәннәр дигән сүзгә ышанасыңмы? Әлбәттә, юк. Ә нигә галәмдәге йолдызлар, планеталар, ай, кояш үзеннән-үзе шундый төгәл тәртип белән урнашкан дигәнгә ышанырга?

Тагын бер мисал – без йөри торган машина. Ул – шактый гына катлаулы механизм һәм аны күрүгә һәркем шушы машина җыела торган заводның булуына, аның акылга ия тере эшчеләр тарафыннан ясалганына иман китерә. Ә кеше, машина белән чагыштырганда, күпкә, бик күпкә катлаулырак төгәл, даһи механизм. Әлбәттә инде, шушы "кеше" дигән искиткеч машина үзеннән-үзе, очраклы гына, илаһи Зат катнашыннан башка җыелган дип әйтү – гап-гади логикага да каршы килә.

Шушы фикерләремне әйткәннән соң, танышым бераз йомшарды сыман, ләкин ничектер киреләнебрәк сорау бирде:

– Сөйләгәннәрең күңелгә ятышлы, кабул итәрлек кебек, ләкин боларга дин тотмыйча да ышанырга буладыр бит инде? Нигә кирәк соң ул дин буенча яшәү?

– Әлбәттә, Аллаһка, Анының барлыгына-берлегенә ышану, иманлы булу – бик әһәмиятле нәрсә. Иманлы кеше – Аллаһы Тәгалә каршында иң дәрәҗәле кешедер. Дин исә – ул кешелеккә Җир йөзендә яшәү өчен бирелгән кагыйдәләрнең тупланмасы, Раббыбызның киңәш-боерыклары, тыюлары. Мәсәлән, әгәр кешеләр юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәнмичә яки белеп тә үтәмичә машинада йөрсә, юлларда нәрсә булыр иде? Ә бүген бик күпләр тиешле таләп-шартларны, кирәкле, мөһим кагыйдәләрне белмичә "кеше" дигән машинада "тормыш" дигән юлдан бара...

Яхшы хуҗа машинасын нәкъ инструкциядә таләп ителгәнчә "тәрбияли": зарарлы нәрсәләрдән саклый, ягулыгын да шушы машинага туры килгәнен генә сала, сикәлтәле, чокырлы юлларны читләтеп узып, яхшы, тигез юлдан барырга тырыша. Адәм баласының да Хуҗасы – аны юктан бар кылган Раббысы, бөек Аллаһы Тәгалә Үзенең акылга ия булган мәхлугы өчен нәрсә файдалы һәм нәрсә зарарлы икәнен аңлатып, "дин" дип аталган махсус Канун биргән. Кеше шул Канун буенча яшәсә, үзенә зыян китерүче нәрсәләрдән котыла, ә файдалы, кирәкле нәрсәләргә ия була. Ә иң мөһиме – үзенең Яратучысы, бөек Хуҗасы ризалыгына ирешә. Шуның нәтиҗәсендә бу дөньяда да, мәңгелек ахирәт тормышында да бәхетле була.

Шулай итеп, безнең бәхет – ул Аллаһ ризалыгына ирешү. Ә дин – шул бәхеткә илтүче бердәнбер дөрес туры юл. "Дин буенча яшәргә кирәк" дигән нәсихәтне ишеткәч, күпләр: "Безнең аңа вакыт юк", – дип җавап кайтарырга ашыга. Уйлап карасаң исә, бу бит "безнең бәхетле булырга вакытыбыз юк" дип әйтү белән бер. Икенчедән, тыелганнан тыелу, рәсүлебез үрнәгендә әхлаклы булу өчен вакыт кирәк түгел.

Һәммәбезгә дә күптән аңларга кирәктер: Аллаһы Тәгалә динне безнең тормышыбызны катлауландырыр өчен түгел, ә киресенчә – җайга салыр һәм җиңеләйтер өчен бирде. Безнең бәхетле булуыбызны теләп, аны безгә бүләк итте!

## Дөнья, уйлан!

…Кинәт кенә бөтен дөнья яктылыкка күмелде. Электрны тоташтырдылар! Сөенечле нурларын сирпи башлаган люстра-яктырткычлар безнең өебезгә генә елмая, шулай да минем бәхет серен искә төшерүдән бар дөнья шатланып яктырган сыман. Ник, урамда төн түгелме соң? Утны сүндердем дә, тәрәзә янына килеп, күккә карадым: анда түптүгәрәк ай балкып тора, йолдызлар җемелди, ә урамда чыннан да караңгы иде.

Шушы манзарага күз салгач, башыма ирексездән бер кызыклы фикер килде. Күп кешенең җанын караңгылык каплаган, ләкин изгелек-игелеккә омтылучыларның кальбендә бервакыт йолдыз кебек иман җемелди башлый. Әгәр игелек кылудан туктасалар, йөрәкләрен янә «төн» баса. Изгелекләрендә дәвамлы булсалар, иманнары көчәя бара һәм бераздан җаннарын тулган ай кебек яктырта башлый. Андый кешеләр Аллаһ рәхмәтендә яши, бернәрсәгә карамастан, үзләрен бик тыныч һәм бәхетле тоя.

Әй Дөнья! Синең җәмәгатең Ахирәт борчыла! Ахирәттәге Җәннәт йортына иман бәхетенә ия булган балаларыбыз гына керә алыр, ди! Уйлан!

…Менә төнге уникене белдереп, сәгать суга башлады. Соң икән шул инде, ятарга кирәк. Тагын бер көн үтте. Ахирәткә таба тагын бер зур адым ясалды.

Сәгатебез уникене сугып, тынды. "Кешелеккә бәхетле булырга вакыт!" – дип Галәм сәгате әле һаман суга…

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе мөдире***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 24.03.12 | 5:04 | 6:34 | 13:02 | 17:05 | 19:06 | 20:36 |
| Якшәмбе | 25.03.12 | 5:02 | 6:32 | 13:02 | 17:06 | 19:08 | 20:38 |
| Дүшәмбе | 26.03.12 | 4:59 | 6:29 | 13:02 | 17:07 | 19:10 | 20:40 |
| Сишәмбе | 27.03.12 | 4:57 | 6:27 | 13:02 | 17:09 | 19:12 | 20:42 |
| Чәршәмбе | 28.03.12 | 4:54 | 6:24 | 13:02 | 17:10 | 19:14 | 20:44 |
| Пәнҗешәмбе | 29.03.12 | 4:51 | 6:21 | 13:02 | 17:11 | 19:16 | 20:46 |
| Җомга | 30.03.12 | 4:49 | 6:19 | 13:02 | 17:13 | 19:18 | 20:48 |
| Шимбә | 31.03.12 | 4:46 | 6:16 | 13:02 | 17:14 | 19:20 | 20:50 |

# Кулъязма әсәрләр тарихыннан

**Идел һәм Кама буе татарларында китап басу һөнәре барлыкка килгәнче, язу культурасына борыннан ия булган халыклардагы кебек, кулдан күчерелгән язма китаплар йөргәнлеге билгеле. Язма китапларны күчереп тарату Болгар дәүләте чорыннан (X йөз) дәвам итеп килгән.**

Идел-Кама буенда яшәгән Болгар, Сарай, Казан дәүләтләре чорында төркичә язылган һәм күчермәләре буыннан-буынга, кулдан-кулга күчеп килеп заманыбызга ирешкән әсәрләр юк түгел. Болгар шагыйре Кол Галинең "Йосыф вә Зөләйхә" атлы кыйссасы (1233), "Шәһри Болгар газыйлары", атаклы "Бәдәвам" белән "Башлагале" ("Кисекбаш") китаплары шундыйлардан санала. Болгар чорында язылып та, нөсхәсе безгә килеп җитмәгән, ләкин исемнәре билгеле булып калган әсәрләр дә бар. Шундыйлардан берсе - Болгарның баш казыйсы Якуб Ногман улы тарафыннан 1112 ел тирәсендә язылган Болгар тарихы.

Аннан соңгы йөзләрдә иҗат ителгән китаплар бик сирәк сакланган. Мәхмүд Гали улы Болгариның "Нәһҗ-әл-фәрадис" ("Оҗмах юлы") китабы күчермәләре (китап 1342 елда Сарай шәһәрендә язылган), шул ук XIV йөздә язган Сәиф Сараи шигырьләре, халыкның авыз иҗатында сакланып килгән "Идегәй" дастаны, 1513 елны Казанда төзелгән Коръән тәфсире-комментариесе (нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана), Казан шагыйре Мөхәммәдъяр Мәхмүд улының "Төхфәи мәрдан" ("Егетләр бүләге") һәм "Нуры содур" ("Күңел нуры") исемле шигырь җыентыклары (1539-1542), Касыйм шәһәрендә Кадыйргали-би тарафыннан гарәпчәдән компиляция тәртибендә 1600 нчы еллар тирәсендә язылган "Гомуми тарих" китабы, шагыйрь Мәүла Колый әсәрләре (1670 нче еллар) кулъязма килеш сакланып килгәннәр.

Шундый китаплар өстенә Урта Азиядән чыгтайдан кергән Рабгузиның "Кыйссасел-әнбия" ("Пәйгамбәрләр тарихы"), "Бабирнамә" ("Бабирның юлъязмалары"), "Шәҗараи төрки" ("Төрки халыкларының нәсел язуы"), Әбелгазый Баһадирхан әсәре кебек тарихлар, үзбәк шагыйрьләреннән Әхмәт Ясәвинең "Диван хикмәт"е, Сөләйман Бакыргани һәм Суфи Аллаһияр вәгазьләре үз вакытында кулъязма килеш таралган.

Көнчыгыш дөньясында, шул исәптән Идел-Кама буе татарларында да, китап күчереп тарату үзәге мәдрәсәләрдә булып килгән. Күчерү эшен шәкертләр үтәгән. Шәкертләрдән тыш, матур язуга сәләтле кешеләр (хаттат-каллиграфлар) дә шөгыльләнгән.

Китап күчерү белән даими эш иткән хаттатлардан Оры авылыннан Иванай Арсай улы (XVII йөз ахыры), Ташкичүдән Илми Үтәмеш улы (1700-1740), Ашыттан Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы (XVIII йөз уртасы), Кыскадан Собхан Мәрҗани (соңгысы үзе генә дә 60 томнан артык китап күчергән) кебекләрнең исемнәре билгеле.

Тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани бабасы хаттат Габделкәримнән калган язма китаплар арасында матур язу остасы бер кыз күчергән китаплар турында: "Язуы гүзәл, эше нәфис һәм күчерүче кызның белеме җитеш булганын күрсәткән кулъязма китаплар бар иде. Ул чакта яшьлегем сәбәпле, шул кызның исемен һәм башка әхвәлен тикшереп яза алмавыма әле дә булса үкенәмен", - ди (Мөстәфадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар. Т. 2. - Казан, 1900).

Китап күчерүче хаттатларның берсе турында Каюм Насыйри яза: "Ул заманнар китап баса торган басмаханәләр юк, халык кулында һәммәсе язган китап булгандыр. Хөсәен баба (Зөя өязе Югары Шырдан авылында) язуга оста кеше булган. Риваять кылалар, Хөсәен баба Әлмөхәммәт улы Коръән күчерүче иде, үзенең гомерендә берничә йөз китап язгандыр, диләр. Аның кулы белән язылган китаплар бәгъзе кешеләр кулында хәзер дә күренәдер. Бу кеше 1805 нче елларда Югары Шырданда вафатдыр" (Каюм Насыйри мәҗмугасы. - Казан, 1956).

Бу мисаллардан ачык күренә ки, язма әсәрләр һәр якның үз хаттатлары аша ил эченә таралган.

Кулларда йөргән язма китапларның зур күпчелеге дини китаплар, дини дәреслекләр, пәйгамбәрләр тарихы кебек әйберләр булган. Арада тарих, сүзлек, медицина китаплары, Иран шагыйре Сәгъди Ширазиның дөньякүләм танылган "Гөлестан"ы һәм "Бостан"ы, "Хөсрәү вә Ширин"нең фарсы тексты, суфичылык рухында язылган "Диван хикмәт", "Сөбателгаҗизин" ("Суфилык карашында нык тору") һәм аңар аңлатмалар, "Бакырган китабы" кебек әдәби әсәрләр күренә.

Язма китаплар эчендә тышлыгы һәм бит башлары көнчыгыш орнаментлары белән бизәлгән нөсхәләр дә бар.

Матур язу остасы Лотфи Өммәти (Әлмәти) күчергән һәм бизәгән "Диван Ризаи"дәге ("Ризаиның шигырьләр җыентыгы") бит башы һәм текст, "Гашыйк Гариб" һәм "Таһир-Зөһрә" тышлыклары шул турыда сөйлиләр.

Баерак кешеләр кулындагы хосусый китапханәләрдә гарәп һәм Иран осталары кулыннан үткән гаять нәфис эшләнгән язма китаплар да аз булмаган.

Китап күчерү эше бездә басмаханәләр ачылганнан соң да дәвам иткән. Исем казанган хаттатлардан Рәхмәт Әмирхан, Мостафа Әлдермеши, Петербург университетының каллиграфия укытучысы Гали Мәхмүдов белән Казан литографиясендә гравер булып эшләүче Лотфи Өммәти кебекләрне күрсәтергә мөмкин. Соңгы икесе көнчыгыш орнаментлары остасы буларак танылганнар.

Кулдан китап күчерү төпченүле һәм вакытны күп ала торган хезмәт булганга, оста куллардан чыккан китаплар кыйммәт бәягә сатылган. Шуңа күрә ул чакларда язма әсәрләр бары тик байлар, мәдрәсә тәрбиясе күргән хәлле кешеләр кулында гына тупланган.

Борыннан килгән кулъязма китаплардан әдәби, тарихи кыйммәте булган кайберләре Көнчыгышны өйрәнүче рус һәм татар галимнәренең тырышлыгы белән табылган. Төркичә кулъязмаларның шактый өлеше Мәскәү, Ленинград, Казан гыйльми китапханәләрендә саклана.

**"Татарча басма сүз" китабыннан кыскартып алынды**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №12 (129) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-528.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 22 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**